**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ТУЙМЕТКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

ул.Школьная ,дом 4, с.Туйметкино, 423108
Мәктәп урамы, 4 нче йорт, Туймәт авылы, 423108
тел./факс email: 8-(84396) 3-72-90. Tuy.Cmn.2@tatar.ru

№ 145 05 март 2025 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Туймәт авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Туймәт
авыл җирлеге Советының
2012 елның 27 декабрендәге
«Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Туймәт
авыл җирлегенең җирдән
файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләрен раслау турында»
№ 38 карарына үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2024 елның 26 декабрендәге № 485-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 27 декабрендәге 38 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктның 2,3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Автомобиль юлының юл буе полосалары - беренче, икенче яисә өченче категорияле автомобиль юлына бүленгән полосага ике яктан да якын урнашкан һәм чикләрендә юл хәрәкәте иминлеге таләпләрен, шулай ук автомобиль юлын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау, карап тотуның, автомобиль юлының үсеш перспективаларын исәпкә алып, аның сакланышының

нормаль шартларын тәэмин итү максатларында җир кишәрлекләреннән (җир кишәрлекләренең өлешләреннән) файдалануның махсус режимы билгеләнә торган территорияләр.

Зона параметрлары һәм зонадагы эшчәнлекне чикләү «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә билгеләнә.

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Туймәт авыл җирлеге
башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары Х.Х. Сәхапова